ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Ленина, д.1а, , 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Ленин урамы, 1а йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 51** **09 декабрь 2019ел**

**Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенең Ак-Юл авылында гражданнар җыены турында 20.11.2019 ел, №2 карарын,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Екатериновка бистәсендә 20.11.2019 ел гражданнар җыенының № 3 карарын,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Тарлау авылында 21.11.2019 ел гражданнар җыенының № 4 карарын,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Алабакул авылында 21.11.2019 ел гражданнар җыенының № 5 карарын,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Яссы-Тугай авылында 22.11.2019 ел гражданнар җыенының № 6 карарын,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Димтамак авылында гражданнар җыенының 23.11.2019 ел, №7,карарын
Тормышка ашыру максатларында, Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Димтамак авыл җирлеге гражданнарының кушымта итеп бирелгән үзара салым акчасы җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендына, Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм http:pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырырга .
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Димтамак авыл җирлеге башлыгы: И.Ә Сәләмов.

Кушымта 1
Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты
карарына
2019 елның 9 декабре, № 51

**Димтамак авыл җирлегенең гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Балачактан инвалидлардан, беренче һәм икенче төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итүгә чакырылучылардан тыш, гражданнарның үзара салым акчалары Димтамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яше тулган гражданнарның гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2020 елның 1 гыйнварыннан 28 февраленә кадәр срокта түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаек сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт булмау,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә, өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерүнамә) бланкы мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук кул кую яки почта элемтәсе чарасына юллау юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Димтамак авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар аша акча күчерү юлы белән Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Кушымта 2
Димтамак авыл җирлеге Башкарма

комитетының 2019 елның 9 декабрендәге
51 номерлы карарына

ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮНАМӘ) № ______

Димтамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И. А.и.
______________________________________________________________________

Адресы: ______________________________________________________________

Гражданнар җыены карары нигезендә _________торак пунктында 2020 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге советы утырышы нигезендә, Сезгә _______ елга кадәр гражданнар җыены чараларын тормышка ашыру өчен _____ сум күләмендәге бер тапкыр түләнелә торган акчаны түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:

Банк получателя
БИК

Получатель
Сч. №
ИНН КПП
КБК
ОКАТО

Назначение платежа **самообложение граждан за 2020 год.**

Җитәкче _________________ ________________________________________
М. У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -**

Хәбәрнамә (Белдерүнамә) № _________________

Димтамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча________________ сум күләмендә бер тапкыр түләнелә торган акчаны түләү турында

(*муниципаль берәмлек исеме*)

Түләүченең Ф.И. А.и. _______________________________________________________

Адресы: ___________________________________________________________________________

Кабул ителде «__» _______________ 20__ елда _______________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әгәр дә хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылса, өзелмә төпсә (отрывной корешок) тутырыла һәм Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетында калдырыла.*